| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ<br>БОЛЬШЕТИГАНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>АЛЕКСЕЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>АЛЕКСЕЕВСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>ЗУР ТИГӘНӘЛЕ АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

Зур Тигәнәле авылы

21.05.2020 № 149

**Үз көчен югалткан дип тану турында**

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 14 маддәсендәге 1 пунктының 3 пунктчасының «б» абзацын үтәү йөзеннән «Татарстан Республикасының аерым закон актларына коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә вазыйфаи затларның аерым категорияләренең катнашу тәртибен камилләштерү өлешендә үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 07 маендагы 20-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы кабул ителүгә бәйле рәвештә

**Зур Тигәнәле авыл җирлеге Советы карар кылды:**

1. Үз көчен югалткан дип танырга:

- Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Зур Тигәнәле авыл җирлеге Советының 2017 елның 25 сентябрендәге 71 номерлы «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Зур Тигәнәле авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан яллаучы (эш бирүче) вәкиленең коммерциячел булмаган оешмалар (сәяси партиядән тыш) белән идарә итүдә бердәм башкарма орган буларак катнашу яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керү өчен бушлай рөхсәтен алу тәртибе турындагы Нигезләмә хакында» карары;

- Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Зур Тигәнәле авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Зур Тигәнәле авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан бер кеше башкара торган башкарма орган сыйфатында коммерциячел булмаган оешмалар (сәяси партиядән тыш) белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның идарә коллегиаль органнары составына керүгә рөхсәт бирү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 23 гыйнварендәге 113 номерлы карары.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталындагы җирлек сайтында урнаштырырга һәм Зур Тигәнәле авыл мәдәният йорты бинасында түбәндәге адрес буенча: Татарстан Республикасы, Алексеевский районы, Зур

Тигәнәле авылы, А.Баттал урамы 17 йорт; "Әшнәк" кибете бинасында түбәндәге адрес буенча: Татарстан Республикасы, Алексеевский районы, Әшнәк авылы, Х.Вахит урамы, 11 йорт махсус мәгълүмат стендында халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Алексеевск муниципаль районы**
**Зур Тигәнәле авыл җирлеге башлыгы,**
**Совет рәисе** **С.Җ.Әхмәтҗанов**